ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

01.06.2021 Казан ш. № 59-од

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 12 июлендәге 91-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең норматив хокукый актын актуальләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 12 июлендәге 91-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта «(ел саен) яңарту» сүзләрен «үзгәртү» сүзенә алмаштырырга;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына Идарә җитәкчесе һәм (яки) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән дә

(кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган бүлекчәдән)), Идарә каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә Идарә җитәкчесенең рәсми мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган, кадр технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча бәйсез экспертлар – тиешле өлкәләрдә һәм граждан хезмәтенең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләрендә белгечләр булып торган фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә. Бәйсез экспертның конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Идарә каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

Идарә каршындагы Иҗтимагый советның конкурс комиссиясе составына кертелә торган вәкилләре Идарә җитәкчесе гаризасы нигезендә әлеге совет карарында билгеләнә.»;

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Конкурс комиссиясе тарафыннан утырышны аның әгъзасы яки кандидаты тәкъдиме белән, мондый карар сәбәбен (нигезен) күрсәтеп, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булган очракта) уздыру турында конкурс комиссиясе карары кабул ителергә мөмкин.

Идарә тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.»;

3.4 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт (эш) урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәте тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданинның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш);»;

җиденче абзацта «эш (хезмәт) урыны» сүзләрен «хезмәт итү (эшләү)» сүзләренә алмаштырырга;

4.11 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«конкурс нәтиҗәләрен Идарәнең һәм Федераль мәгълүмат системасы сайтларында бастырып чыгару.»;

4.12 пунктта «конкурс комиссиясе бәяли» сүзләрен алда «һөнәри дәрәҗәсен» сүзләрен өстәргә;

4.12.1 пунктта таблицадан соң беренче абзацта «10 балл» сүзләреннән соң «, минималь балл – 0» сүзләрен өстәргә;

4.12.3 пунктта алтынчы абзацта «10 балл» сүзләреннән соң «, минималь балл – 0» сүзләрен өстәргә;

4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Кандидатның ахыргы баллы кандидатка конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси әңгәмә, башка конкурс биремнәрен бәяләү нәтиҗәләре буенча

куелган балларның һәм кандидатның тест һәм башка төрле аналогик, нәтиҗәләрнең формалаштырылган исәпләмәсен күздә тоткан конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча җыелган балларның уртача арифметик суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның ахыргы балларын чагыштыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе сәркатибе аларның йомгаклау балларын кимету тәртибендә кандидатлар рейтингын төзи.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең конкурс комиссиясендә өч елдан артык булган бәйсез эксперт үз вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклый дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуда үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
Баш ветеринария идарәсе
җитәкчесе А.Г. Хисаметдинов